КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 сентябрь г.Казань № 1184

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карары белән расланган «Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында приз алучыларны һәм җиңүчеләрне әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм күрсәтү» гранты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 ноябрь, 1078 нче; 2022 ел, 29 июнь, 613 нче, 2022 ел, 2 сентябрь, 956 нчы, 2023 ел, 3 февраль, 92 нче, 2023 ел, 24 апрель, 520 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында приз алучыларны һәм җиңүчеләрне әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм күрсәтү» гранты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацында «, йә җиңүчеләрнең, йә абсолют җиңүчеләрнең» сүзләрен «йә җиңүчеләрнең» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Грант Мәктәп укучыларының бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабында җиңүче дип яки призер дип танылган грант алучы әзерләгән һәр укучы өчен 86,0 мең сум күләмендә (физик затлар керемнәренә салымны исәпкә алып) бер мәртәбә түләнә.

Грант бирү грант алучыларның Россия кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

5, 6 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктның бишенче абзацында «, йә җиңүчеләрнең, йә абсолют җиңүчеләрнең» сүзләрен «йә җиңүчеләрнең» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта «абсолют җиңүчеләрнең» сүзләрен төшереп калдырырга;

18 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грантны кире кайтару очраклары һәм тәртибе;»;

тугызынчы - унберенче абзацлар үз көчләрен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин